**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының кайбер указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясе турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 июнендәге ПУ-570 номерлы, 2017 елның 1 июлендәге ПУ-596 номерлы, 2019 елның 25 маендагы ПУ-298 номерлы, 2021 елның 9 апрелендәге ПУ-278 номерлы һәм 2022 елның 5 февралендәге ПУ-90 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 5 июнендәге 385 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.Т. Әйделдиновны, Р.Р. Кыямовны, М.Х. Сәлаховны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Галиев Дамир Расил улын – «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директорын (килешү буенча);

Миңнеханов Рифкать Нургали улын – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президентын (килешү буенча);

Якупов Шамил Наил улын – «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

в) Совет әгъзасы Ю.М. Казаковның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитетын төзү турында» 2022 елның 10 ноябрендәге ПУ-796 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты турында нигезләмәдә:

5 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты (алга таба – Республика координация комитеты) составында:

Республика координация комитеты составыннан А.Т. Әйделдиновны, М.Х. Сәлаховны чыгарырга;

Республика координация комитеты составына Галиев Дамир Расил улын – «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директорын (килешү буенча) кертергә;

Республика координация комитеты әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Х. Гыйльметдиновның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Республика координация комитеты рәистәше»;

Т.Л. Алибаевның – «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

А.М. Әхмәтованың – «Казан талантлар ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча)»;

Ю.М. Казаковның – «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты (килешү буенча)».

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 10 февраль
№ 106